**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Югары Шубан авыл җирлегенең Зур Лызи 2 нче өлеш авылында**

**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

2023 елның 30 ноябре. №2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Югары Шубан авыл җирлегенең Зур Лызи 2 нче өлеш авылында **халык җыены карар бирә**:

1. Россия Федерациясе кораллы көчләренә мобилизацияләнгән гражданнарга һәм аларның гаилә әгъзаларына узарасалымның 90% һәм 50% күләмендә ташлама билгеләнгән 1 төркем инвалидлардан, көндезге бүлектә белем алучы студентлардан, 90 яшьтән өлкәнрәкләрдән, авырып ялгыз яшәгән өлкән пенсионерлардан һәм тыл хезмәтчәннәреннән кала, Шубан авыл җирлегенен Зур Лызи 2 нче өлеш авылында теркәлгән,балигъ булган һәр гражданга 2024 елда узарасалымны 500 сум күләмендә кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирлектә әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

- артезиан скважинасы өчен ЭЦВ 6-6,5-85 маркалы тирәнлек насосы сатып алу;
- Зур Лызи 2 өлеш авылындагы Шушма елгасы аша асылмалы күперне өлешчә ремонтлау.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Шубан авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга, http:// pravo.tatarstan.ru. Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында, Балтач муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Муниципаль берәмлек башлыгы,
Совет Рәисе: С.З.Васильева.